КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 июнь г.Казань № 412

«БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын уздыру көннәрендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын уздырганда иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасы ярышлары узган көннәрдә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр спорт объектларына якын территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларында, кушымта нигезендә, алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми дип билгеләргә, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш.https://internet.garant.ru/ - /document/408559573/entry/100

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, кертелә торган чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм, килештереп, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 июнь, 412 нче
карарына кушымта

Спорт объектларына якын территорияләрдә урнашкан сәүдә объектларының урнашкан урыны

| Т/с | Спорт объектының адресы һәм исеме | Алкогольле продукцияне сатуны чикләү даталары | Сәүдә объектлары адреслары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | «Су спорт төрләре сарае» укыту-спорт комплексы,<br>Казан шәһәре, Сибгат Хәким ур., 70 й. | 13.06.2024 – 18.06.2024 | Казан шәһәре, Сибгат Хәким ур., 51 й.;<br>Адоратский ур., 1А, 2, 2Б йортлары;<br>Чистай ур., 73, 77/2, 79 йортлар;<br>Нигъмәтуллин ур., 3, 11/84 йортлар |
| 2. | Федераль гимнастика спорт-тренировка үзәге,<br>Казан шәһәре, Сыртланова ур., 6 й. | 13.06.2024 – 15.06.2024,<br>20.06.2024 – 22.06.2024 | Казан шәһәре, Гарифьянов ур., 4, 28А, 28Б, 34 йортлар;<br>Сыртланова ур., 8, 16 йортлар;<br>Хөсәен Мәүлетов ур., 21А, 29, 31В, 42, 46 йортлар;<br>Академик Парин ур., 6/1 й.;<br>Юлиус Фучик ур., 49 й.;<br>Җиңү проспекты, 17, 19 йортлар |
| 3. | «Татнефть Арена» боз спорт сарае,<br>Казан шәhщре, Чистай ур., 42 й. | 13.06.2024 – 16.06.2024,<br>21.06.2024 – 22.06.2024 | Казан шәhщре, Мусин ур., 9А й.<br>Чистай ур., 25, 33А, 36, 38, 43, 43А, 53А йортлар |
| 4. | "Санкт-Петербург" волейбол үзәге,<br>Казан шәһәре, Мидхәт Булатов ур., 1 й. | 14.06.2024 – 15.06.2024, | Казан шәһәре, Мидхәт Булатов ур., 1А й.; |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | 19.06.2024 – 22.06.2024 | Бакый Урманче ур., 4 (3, 4 корп.), 5, 6, 7, 8, 11 (2 корп.) йортлар;<br>Гариф Ахунов ур., 2, 6 йортлар |
| 5. | «Тулпар» универсаль спорт комплексы,<br>Казан шәһәре, Рәүис Гәрәев ур., 80 й. | 13.06.2024 – 15.06.2024 | Казан шәһәре, Рәүис Гәрәев ур., 90 (1 корп.), 92, 96, 103, 107, 108 йортлар |
| 6. | «Бадминтон үзәге» спорт комплексы,<br>Казан шәһәре, Оренбург тракты ур., 99 й. | 13.06.2024 – 16.06.2024 | Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 18Б, 24А йортлар;<br>Академик Парин урамы, 16, 22 йортлар<br>Дубравная ур., 51Г й. |
| 7. | «Казан теннис академиясе» укыту-спорт комплексы,<br>Казан шәһәре, Оренбург тракты ур., 101 й. | 13.06.2024 – 19.06.2024 | Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 18Б, 24А йортлар;<br>Академик Парин урамы, 16, 22 йортлар<br>Дубравная ур., 51Г й. |
| 8. | «Бокс һәм өстәл теннисы үзәге» спорт комплексы,<br>Казан шәһәре, Җәүдәт Фәйзи ур., 2А й. | 13.06.2024 – 16.06.2024, 19.06.2024 – 22.06.2024 | Казан шәһ., Магистраль ур., 15 й.;<br>Академик Глушко ур., 22, 22Г, 28 (1001 пом.), 35, 41А, 43, 47А, 47Г йортлар;<br>Хәйдәр Бигичев ур., 25А, 30, 34, 35А йортлар;<br>Җәүдәт Фәйзи ур., 15 й.;<br>Дуслык тык., 2 й. (1 корп.) |
| 9. | «Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк,<br>Казан шәһәре, Спартак ур., 2 й. | 18.06.2024 – 21.06.2024 | Казан шәһәре, Һади Такташ ур., 2, 77 йортлар;<br>Спартак ур., 6 й.;<br>Марсель Сәлимҗанов ур., 12А, 15/8В, 17 йортлар |
| 10. | «Казан» халыкара ат спорты комплексы,<br>Казан шәһәре, Патрис Лумумба ур., 47А й. (1 корп.) | 19.06.2024 – 20.06.2024 | Казан шәһәре, Альберт Камалеев пр., 28/9, 30, 32, 32Б, 34 йортлар;<br>Габдулла Кариев ур., 3, 4 йортлар;<br>Тулпар ур., 5 й. |
| 11. | «Ак Барс» көрәш сарае,<br>Казан шәһәре, Фатыйх Әмирхан ур., 1Г й. | 13.06.2024 – 14.06.2024, | Казан шәһәре, Алексей Козин ур., 2 й.;<br>Сибгат Хәким ур., 44 й. |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | 17.06.2024 – 22.06.2024 | |
| 12. | «Баскет-холл» баскетбол спорт корылмасы, Казан шәһәре, Спартак ур., 1 й. | 15.06.2024 – 18.06.2024, 20.06.2024 – 22.06.2024 | Казан шәһәре, Петербург ур., 9, 42 йортлар;<br>Спартак ур., 2 (1 корп.), 6  йортлар;<br>Һади Такташ ур., 2, 77 йортлар;<br>Марсель Сәлимҗанов ур., 12А, 15/8В, 17 йортлар |